СОВЕТ ОЛУЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ш. Маннура, д.72 а, с. Олуяз, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422146

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ш. Маннур ур., 72 а нче йорт, Олыяз авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422146

тел.(факс): (85563) 2-25-82; e-mail: Olu.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар
№ 3-2

Решение
17.11.2020 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Советының 2016 елның өченче мартындагы 1-7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягәкаршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге №273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2019 елның 16 декабрендәге «Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 439-ФЗ номерлыФедераль закон, 2020 елның 31 июлендәге«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»268-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Советының 2016 елның өченчемартындагы1-7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (18.11.2016 ел №2-16, 15.05.2017ел № 1-21, 28.07.2017ел №3-22, 14.11.2017ел № 2-26, 05.06.2018ел № 2-32; 13.08.2018 ел № 2-34, 20.11.2018 ел № 3-37.12.2018 ел № 2-38, 21.03.2019 ел №1-40 18.09.2019 ел №3-45 19.02.2020 № 1-50 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.12.3 пунктның 4 пунктчасында «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яки) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар» сүзләрен өстәргә;

1.2.24.2 пунктының 4 пунктчасынатүбәндәгесүзләр өстәргә:

«(булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узганчорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминиятесистемасындаиндивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе

законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү»;

2.Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгы И.Я.Хаевка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе И.Я.Хаев